БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

# ДУСЛЫК

КПССның ОКТЯБРЬ РАЙКОМЫ һӘМ ХАЛЫК ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ РАЙОН СОВЕТЫ ОРГАНЫ

ОРГАН ОКТЯБРЬСКОГО РАЙКОМА КПСС И РАЙОННОГО СОВЕТА НАРОДНЫХ ДЕПУТАТОВ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №17 (7034) | 10 февраль, 1990 ел. ШИМБӘ | Бәясе 3 тиен.

## Уңышлы үтәделәр

«Татжилгражданстрой» РСУсы коллективы январь ае планнарын уңышлы үтәде. Планда каралган 110 мең сум урынына 126 мең сумлык капиталь ремонт эшләре башкарды.

Планнарны үтәүдә Петр Трофимович Макушенко цехы һәм Мәсәния Солтанова җитәкчелегендәге штукатур-буяучылар бригадасы үзләреннән аеруча зур өлеш керттеләр.

### Депутатлыкка кандидатлар белән очрашулар

## Сораулар күп булды

8 февральдә район культура йортында 868 нче Чирмешән территориаль сайлау округы буенча РСФСР халык депутатлыгына кандидатлар белән очрашу булды.

Очрашуда беренче булып сүз алган лениногорскилы врач Ю. В. Тихонов Е. А. Шәрифуллинаның тормыш һәм хезмәт эшчәнлеге турында сөйли.

—Үзгәртеп корулар дәүләт власте органнарына да яңа кешеләрне таләп итә,—ди кандидатның ышанычлысы. — Елена Александровна шундый вәкил: тынгысыз хезмәтче, җәмәгать эшендә актив. Яшьлеге, интеллигентлыгы, эшлеклелек сыйфатлары аның республика дәүләт власте югары органнарында лаек вәкил буласына ышаныч тудыра.

Депутатлыкка кандидат Е. А. Шәрифуллина сайлау алды платформасында актив, социаль политика мәсьәләсе гаять мөһим бурыч икәнлегенә басым ясады. Аның платформасында экология һәм демократияне үстерү мәсьәләләре игътибар үзәгендә торды.

—Бүген җәмгыятебез үсешендә теге яки бу кимчелекне күрү һәм тәнкыйтьләү генә аз, аларны төзәтү буенча эшләү кирәк, —диде үзенең чыгышында икенче кандидат П. А. Тимирясовның ышанычлысы Н. С. Фролов. —Бу яктан мин яклаган кандидат Тимирясовның өстенлекләре шактый. Ул үзе югары белемле, арендачы, шуңа күрә аның бәйсез булачагына, халык ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен тырышачагына ышанам.

Кандидат П. А. Тимирясов үзенең авылда туып үсүен, аның бүгенге кыен проблемалары турында сөйләде. Авыл аның күңеленә якын, аны ул хуҗалык итүнең төрле формаларын киң куллаunion үстерү мөмкинлеген билгеләп уза.

Т. Г. Гыймадиев, ышанычлысы буларак, якташыбыз М. М. Мусинның тормыш юлын тасвирлый, аның хезмәт сөючәнлегенә, җәмәгать эшендә активлыгына басым ясый.

—Авылның проблемалары күп төрле,—диде Миндамир Мәхмүтович үзе дә. —Менә бер генә мисал. 1986 елда шикәр чөгендере комбайнының бәясе 9700 сум булса, былтыр 24300 сумга күтәрелде. Шуңа күрә депутат булып сайлана калсам, авылда тормышны яхшыртуга аеруча басым ясаячакмын. Авылда торак төзү, газ кертү, җылы гаражлар төзү, хатын-кызлар хезмәтен җиңеләйтү мәсьәләләрен игътибар үзәгендә тотачакмын.

Аннан соң сүз алган Ә. К. Сафиуллин депутатлыкка кандидатларның чыгышын анализлап, конкрет районыбыз проблемаларына игътибар аз бирелүен күрсәтеп уза.

547 нче ПМКдан төзүче Н. Куприянов кандидатларның үз чыгышларында яшьләр проблемаларына тукталмауларын күрсәтеп, үзенең соравын бирә. НГДУдан О. Долгов соравы да аныкына авазداш иде.

Очрашу барышында кандидатларга язма сораулар да күп керде. Алар буенча кандидатлар конкрет җаваплар бирделәр.

* * *

Бу кандидатлар белән шундый ук очрашу Биләр Озерода да булып үтте.

**Р. АЙЗАТУЛЛИН.**

## Ирешелгәннәр белән чикләнмиләр

Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә хезмәтчәннәре икеләтә энергия һәм тырышлык белән эшлиләр. Еллык планнарны һәм кабул итеп алынган йөкләмәләрне үтәү өчен алар вакыт белән исәпләшмиләр. Январь аенда биредә терлекләрдән уртача 1000 грамм тәүлеклек артым алуга ирештеләр.

Хуҗалык 1989 елда дәүләткә барлыгы 8600 центнер ит тапшырырга тиеш булса, фактта исә 9870 центнер ит озатты. План 109,5 процентка үтәлде. 1989 елның 1 январеннан агымдагы елның 1 январенә кадәр хезмәт күрсәткечләре буенча терлекчеләрдән Харрас Яруллин, Газиз Билданов, Ильяс Шәрипов һәм икенче комплекстан Мәрбия Туктамышева, Гөлнәзирә Билданова, Галия Мусина җиңүчеләр дип табылдылар. Бу ике группаның да терлекчеләре 280 шәр баш мөгезле эре терлек симертеп 1086—1043 грамм тәүлеклек артым алдылар.

Хезмәт җитештерүчәнлеге күзгә күренеп үсте. План буенча ул бер кешегә 9.461 сум туры килсә, 1989 елда 17.430 сумга күтәрелде. Продукциянең үзкыйммәте 145 сум 90 тиеннән 135 сум 76 тиенгә кимеде. Терлекләргә планда каралганча 8,5 центнер азык бирәмлеге сарыф ителде. Рентабельлелек планы 15,9 процент урынына 46,6 процентка үтәлде.

Мөгезле эре терлек симертү буенча хуҗалыкара берләшмә коллективы моның белән генә чикләнмичә, алда тагын да биегрәк үрләрне яулауны максат итеп куйды.


**Г. ЛОТФУЛЛИНА,**
экономист.

## Югары темп белән

Машина төзү заводы коллективы агымдагы елны матур күрсәткечләр белән башлап җибәрде. Январь аенда халык куллануы товарлары 230 мең сум урынына 236 мең сумга, ә чистарту корылмалары өчен җиһазлар эшләү планы 165 мең сум урынына 205 мең сумга үтәлде.

А. Н. Тихонов җитәкчелегендәге бригада югары темп белән эшләп «Струя-Н» һәм КУТМ-120 җайланмаларын үз вакытында әзерләп өлгертте. Бирелә әретеп ябыштыручылардан В.Н. Филиппов, А. П. Глухов, В. М. Яфановның өлеше аеруча зур булды.

**А. СКИДАНЕНКО,**
баш экономист.



Миннегөл Сафиуллинаның гомер юлы туган колхозында уза. Фермага эшкә килүенә дә күп еллар узган инде. Сыер савучы һөнәренең барлык нечкәлекләренә дә күптән өйрәнде, үзе белән янәшәдә эшләүче күп яшьләрне мул продукт алу серләренә төшендерде.

Миннегөл Хәбибулловна районның дүртменчеләре сафында атлады. Узган ел йомгаклары да сөенечле булды. Колхоз савучыларының социалистик ярышында икенче урында иде. Тәҗрибәле савучы быел да мул продукция ала. Январь аенда һәр сыердан көн саен 10 килограмм сөт сауды, ә хәзер аның группасында савым 11 әр килограмм тәшкил итә.

Рәсемдә: Муса Җәлил исемендәге колхоз савучысы М. Сафиуллина.

## Старт алынды

Яңа елның беренче ае тәмамланды. Район элемтә узелы работниклары эштә яхшы старт алдылар. Төп күрсәткечләрнең берсе—табыш тарифы коллектив тарафыннан 101,9 процентка үтәлде, халыктан алынган доход буенча да план тормышка ашырылды. Монда авыл элемтә бүлекләре начальниклары Төрнәс авылыннан Ә.Фәйзуллина, Кычытканлыдан Г. Сәйфетдинова, Яңа Әмзәдән Р. Мәхмүтова һәм шулай ук шәһәрнең икенче элемтә бүлекчәсе начальнигы Р. Биктимирова зур өлеш керттеләр.

Бигрәк тә, иң яшь работник Рәхилә Мәхмүтова турында җылы сүзләр Яңа Әмзә элемтә бүлекчәсенә мәктәпне тәмамлауга килде ул. Монда бер елдан артык эшли, хезмәтен яхшы үзләштерде, эшендә ялгышлыклар җибәрми, җиткерелгән планны даими үти. Бик тырыш, клиентлар арасында ихтирам казанды.

**И. ЛЕТФУЛЛИНА,**
район элемтә узелы экономисты.

## Беренче нәтиҗәләр

Агымдагы елның беренче аенда Норлат-Октябрь элеваторы начар эшләмәде. Төп күрсәткечләрнең берсе—йөк әйләнеше планы 116 процентка үтәлде. Хезмәт җитештерүчәнлеге үсте. Катнаш азык җитештерү һәм реализацияләү планы да арттырып үтәлде. 160000 сумлык керем алынды. Бу—планлаштырылганнан 5 процентка артык. Монда әзер продукцияләр склады мастеры А. И. Синицынның да өлеше зур. Ул төяүбушату эшләрен әйбәт оештырганга вагоннарның һәм автотранспортның тик торуына юл куелмый.

Тракторчы Н. К. Савгельдин һәм дозаторчы В. П. Вертушкина да начар эшләмиләр. Алар икесе дә үз хезмәтләренә намус белән карыйлар, теләсә нинди эшне карусыз башкаралар һәм норманы арттырып үтиләр.

**Р. НОТФУЛЛИН,**
экономист.

## *Әйбәт хезмәт күрсәтәләр*

Ит комбинаты коллективы 1990 елга яхшы старт алды.

Барлык техник-экономик күрсәткечләр буенча план январь аена 150 процентка кадәр үтәлде, шул исәптән сөяк оны планы—150 проценттан артык, ә тулай продукция — 100 процентка җиткерелде.

Бер эшчегә җитештерелгән тулай продукция 10 мең сум тәшкил итә.

Әүвәлгечә, төп производство цехлары, алар—сөю цехы, колбаса ясау цехы һәм суыткычларда хезмәт күрсәтүче уңганнар планны үтәүдә иң зур өлеш керттеләр.

**И. ЕРЕПОВ.**

## Икесе дә уңганнар

«Татарстан» колхозында эштә тырыш һәм мактаулы колхозчы хатын-кызлар шактый. Әминә Гыйниятуллина һәм Фәүзия Хәрләмова шундыйлардан. Алар колхозда төрле эшкә йөриләр: җәен чөгендер басуыннан кайтып кермиләр, ә кышын исә фермага алмаш савучы булып эшкә баралар. Алар һәрчак үз эшләрен җиренә җиткереп башкаралар. Бу ике уңганның авызыннан беркайчан да зарлану сүзләре чыкмас. Чөнки алар икесе дә эштә сыналганнар.

Гомер буе колхоз производствосында намуслы хезмәт куйган бу хатын-кызларга уңышлар телибез.

**З. ИСМӘГЫЙЛЕВА,**
хәбәрче.

# 1990 елның 4 марты—халык депутатларын сайлаулар көне

## Татарстан АССРга халык депутатлыгына безнең кандидатлар

### 225 нче Биләр Озеро сайлау округы буенча халык депутатлыгына кандидат

# МОРАДЫЙМОВ ХӘЛИЛ ХӘМЗИЕВИЧ



Хәлил Хәмзиевич Морадыймов 1955 елда Татарстанның Октябрь районы Чишмә поселогында туа. Милләте буенча татар. 1979 елдан КПСС члены.

Хезмәт юлын 1971 елда Октябрь районының «Дружба» колхозында терлекче булып башлый.

1974—1976 елларда Совет Армиясе сафларында хезмәт итә.

Тәтеш совхоз-техникумын тәмамлагач, 1977 елда «Дружба» колхозында агроном, комплекслы бригада бригадиры, председательнең азык җитештерү буенча урынбасары булып эшли.

1980 елда Октябрь районының «Рассвет» совхозына директор итеп билгеләнә.

Шунда ул үзен оештыру сәләтенә оста, профессиональ хәзерлекле, инициативалы, тәҗрибәле, авыл хуҗалыгы производствосын яхшы белүче җитәкче буларак танытты.

Уңай сыйфатларын искә алып, аны 1983 елда КПССның Октябрь райкомына авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире итеп расладылар. Шул ук 1983 елда ул «Дружба» (хәзерге Хафизов исемендәге) колхозына председатель итеп сайланды.

1985 елда Хәлил Хәмзиевич читтән торып Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлый.

Иптәш Х. Х. Морадыймов колхоз производствосын идарә итүдә һәм оештыруда алдынгы алымнар кертүгә зур әһәмият бирә.

1986 елда КПСС Өлкә комитеты аппаратына эшкә чакырыла. 1987 елның февраль аенда КПСCның Октябрь райкомының беренче секретаре итеп сайлана.

Х. Х. Морадыймов демократизацияләүдә, сайлаулы партия активы эшен активлаштыруда, халык үтенечен өйрәнүдә, социаль гаделлек урнаштыруда максатчан эш алып бара. Районның социаль-экономик үсешенә, азык-төлек программасын үтәүгә, партия органнарында эшләү стилен һәм методларын камилләштерүгә, кадрларны тәрбияләү эшенә күп көч куя.

Х. Х. Морадыймов КПСС Өлкә комитеты членлыгына кандидат, ТАССР Верховный Советы депутаты, халык депутатларының район Советы башкарма комитеты члены.

Хафизов исемендәге, Муса Җәлил исемендәге колхозлар, «Рассвет» совхозы хезмәт коллективлары Хәлил Хәмзиевич Морадыймовны 225 нче Биләр Озеро сайлау округы буенча ТАССРның халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәттеләр.

## Х. Х. Морадыймовның сайлау алды платформасының төп положениеләре

Минем эшчәнлегемнең төп юнәлеше Октябрь район партия оешмасының сайлау алды платформасында ачык чагыла. Ул җирле матбугатта басылып чыкты. Яңадан кабатламас өчен, игътибарны кайбер мәсьәләләргә генә юнәлдерергә телим.

Хәзерге вакытта үзгәртеп кору идеяләрен практикада тормышка ашыру—иң мөһим һәм принципиаль мәсьәлә, кешегә, аның мәнфәгатьләренә һәм ихтыяҗларына таба кискен борылу иң әһәмиятле һәм социаль гадел проблема булып тора.

Коммунист, гражданин буларак, үземнең максатымны һәм бурычларымны үзгәртеп коруларны тирәнәйтүдә, районның социаль-экономик үсешен тизләтүдә күрәм. Шул ук вакытта кешенең социаль һәм рухи активлыгын күтәрүгә хезмәт итә торган демократияләштерү мөмкинлекләреннән тулысынча файдаланырга кирәк дип саныйм.

Минем өчен иң мөһим мәсьәлә — район халкының тормыш-көнкүрешен яхшырту. Бу проблема бөтен социаль-экономик политиканың үзәгендә тора һәм азык-төлек мәсьәләсен хәл итүне иң беренче планга куя.

Азык-төлек проблемасын авылның социаль сферасы үсешеннән башка хәл итү мөмкин түгел, шунлыктан халык депутатының эшчәнлегендә бу шулай ук мөһим мәсьәлә булып тора.

Авылны үзгәртеп коруда без бөтен проблемаларны комплекслы хәл итүгә ориентация алырга тиешбез.

Авылда тормыш шартлары шәһәрнекенә якынаерга тиеш.

Азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту, игенчелек һәм терлекчелек үсешенең юллары КПСС райкомы пленумында эшләнгән программаларда билгеләнде.

Анда игенчелек культурасын һәм уңдырышлылыкны үстерү нигезендә барлык төр культураларның уңышын арттыру, терлекләрнең продуктлылыгын күтәрү каралган. Рациональ куллану нормаларына ирешү өчен җитештерү дә ел саен кимендә 10 процентка артырга тиеш.

Авыл хуҗалыгы производствосын интенсивлаштыру фән һәм техника казанышларын кертүне таләп итә.

Мин яхшы аңлыйм: кайбер мәсьәләләр республика органнары белән бергә хәл итүне сорый.

Аренда подряды, шул исәптән гаилә һәм туганлык нигезендә, подряд зур мөмкинлекләргә ия.

Азык-төлек программасын реализацияләү—ул, һичшиксез, бөтен халык эше, моңа шәхси хуҗалыкларны тарту да бик мөһим.

Шул максатларны күздә тотып шәхси хуҗалыкларны алып бару өчен хезмәт күрсәтүне киңәйтү, терлек-туар, кош-корт тоту, бакчаларны эшкәртү өчен шартлар булдыру, бигрәк тә торак йортлар төзү кирәк дип саныйм.

Халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, медицина ярдәменең сыйфатын күтәрү, райондагы һәр кешегә аны кулланырга мөмкинлек тудыруны шулай ук иң мөһим мәсьәләләрнең берсе дип саныйм. Моның өчен сәламәтлек саклау учреждениеләренең материаль-техник базаларын ныгытырга һәм үстерергә, аларны кадрлар белән тәэмин итәргә кирәк. Медицина хезмәткәрләрен районда ныгыту өчен сәламәтлек саклау объектларын аларга торак йортлар төзү белән бергә үк алып барырга кирәк.

Картлар, ялгызлар һәм инвалидларның тормыш шартларын яхшырту, аларны азык-төлек продуктлары, медикаментлар белән тәэмин итү—безнең бурычыбыз.

Торак пунктларны төзекләндерү юнәлеше турында аерым әйтәсе килә. Бишьеллыкның азагына кадәр бөтен хуҗалыкларны каты түшәүле юллар белән тоташтыру, һәр авылга юллар төзү һәм авыл урамнарын асфальт белән түшәү мәсьәләләре алда тора.

Авыл кешеләренең башка авырлыклары турында да кайгыртырга кирәк. Аерым алганда, хатын-кызларның хезмәтен, көнкүрешен җиңеләйтү, картларның элементар тормыш-көнкүрешен кайгырту күп эш таләп итә. Бүген эш турында лозунглар, чакырулар түгел, ә эш үзе кирәк.

Тормышыбызның рухи һәм культура үсеше проблемалары барыбызда да җитди борчу тудыра. Сәламәт тормыш рәвешен, аңлы ихтыяҗлар, кешенең рухи сафлыгын булдыру буенча районда үткән елларда башланган эшне нык дәвам итәргә кирәк. Болар эчүчелектән чыгу юлларын ачар, халыкның культура байлыклары, сәнгать һәм спортка катнашуы өчен шартлар тудырыр иде.

Авылда бу мәсьәләләр аеруча мөһим. Авыл кешесе, андагы интеллигенция үзләрен социаль яктан ким сизәргә тиеш түгел.

Соңгы вакытта нәрсәләр эшләнде соң? Районда 2 ел рәттән клуб учреждениеләре төзү планы үтәлә, ремонтлау эшләре дә җайлана. Шуны әйтәсе килә, бу программаны тормышка ашыру өчен киләчәктә дә бөтен көчемне куячакмын.

Авыл мәктәбе сүздә генә түгел, ә чынлап торып аерым игътибарны сорый. Мин биредә дә үземнең бурычымны халык мәгарифе органнарына кирәкле ярдәмне күрсәтүдә, кадрлар хәзерләүдә һәм аларның районда калуын тәэмин итүдә күрәм. Бу проблемага хуҗалык органнарының да катнашуы кирәк. Тик халык мәгарифендәге хәлне средстволар бирүне арттырмыйча үзгәртеп булмавын да мин яхшы аңлыйм.

Шул максатлар өчен районда бюджеттан тыш фонд булдырып без дөрес эшлибез.

Милләтара мөнәсәбәтләрне камилләштерү һәм гармонияләштерү— властьнең югары орган вәкиле буларак һәр депутат эшендә мөһим участок. Безгә халыкның милли культура ихтыяҗларын тормышка ашыру өчен мөмкин кадәр күбрәк уңайлыклар тудырырга кирәк. Иң элек В. И. Ленин ватанында яшәгән һәр милләт вәкиленә туган телен өйрәнү, рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен үз халкының, тугандаш халыкларның, дөнья культурасының иң яхшы үрнәкләре белән танышу мөмкинлекләре турында сүз бара.

Бу эшләрне халыкның милли хисләренә кагылмыйча, аерым культураларны өскә чөймичә, бернинди диктатсыз һәм мәҗбүр итмичә алып барырга кирәк. Безгә кешеләрне берләштерүче бөтен нәрсәне хупларга, ә аларны аеручы һәр нәрсәне кире кагарга кирәк.

Оештыру ягыннан нык булмаса, халык хуплавын тапмаса, теләсә нинди, хәтта иң гади программа да һавада эленеп калачак. Алда күп эшләр тора: масштаблы да, көндәлек тә, ә сайлаучылар өчен барыннан да бигрәк аның практик нәтиҗәләре мөһим.

Партия оешмаларының, хезмәт коллективларының хуплавына таянып, үземнең эшчәнлегемне аларның фикерләре, тәҗрибәләре белән чагыштырып, сайлаучыларның ышанычларын аклау өчен бөтен тырышлыгымны куячакмын.

Яшьләр адресына шелтәләр әзрәк булсын өчен, аларның мәнфәгатьләре белән санашырга кирәк. Педагогик коллективларның һәм хокук саклау органнарының, җәмәгатьчелекнең һәм хезмәт коллективларының көчен кулланып, аларны клублар, спорт үзәкләре төзү буенча актив эшчәнлеккә тартырга.

Рухи атмосфераны сәламәтләндерү, эшче контроленең ролен күтәрү һәм тормышның барлык өлкәләрендә социаль гаделсезлекне булдырмау максатында, хәбәрдарлыкны киңәйтү өчен нык торачакмын.

Экология өлкәсендә хәл ителмәгән мәсьәләләр күп әле. Шуңа күрә районны, Кондырча һәм Чирмешән елгаларының экология хәлен сәламәтләндерү программасын тормышка ашыру һәм шикәр заводы поселогында чистарту корылмалары төзү позициясендә нык торырга уйлыйм.

Бигрәк тә безнең җәмгыятьтә торгынлык чорында тамыр җәйгән социаль гаделсезлек күренешләре борчый мине. Кызганычка каршы, безнең илдә хәерчелек чигендә яшәүче пенсионерлар да шактый әле. Әгәр мин депутат булып сайлансам, кичекмәстән округ территориясендә яшәүче пенсионерларның исемлеген төзиячәкмен, аларның тормыш шартларын яхшырту өчен кайгыртырга тырышачакмын.

Безнең республикада яшәүче милләтләрнең һәм халыкларның берсенең дә хокукларын чикләүгә юл куймаска һәм милли политиканың ленинчыл принципларын нык саклау позициясендә торырга уйлыйм.

Бу теләкләрне җәмәгатьчелекнең һәм округтагы барлык сайлаучыларның актив яклаулары нәтиҗәсендә генә тормышка ашырырга мөмкин. Мин сайлаучыларның нык яклавына исәп тотам.



# Любовь Никифоровна Газизуллина

Любовь Никифоровна Газизуллина 1941 елда Чиләбе өлкәсенең Карабаш шәһәрендә туган. Милләте буенча рус. 1970 елдан КПСС члены.

Хезмәт эшчәнлеген 1960 елда Уссури тимер юл техникумын тәмамлагач, Сахалин өлкәсенең Синегорск станциясе буенча дежур булып башлый. 1961 елда Көньяк Сахалин шәһәре тимер юл идарәсе буенча дежурлык каршында оператор вазифасына күчерелә.

Любовь Никифоровна 1964 елдан Октябрь районында станция буенча дежурный, йөкләр двовы мөдире, станция начальнигы урынбасары, ә 1969 елдан бүгенге көнгә кадәр Куйбышев тимер юлының Норлат станциясе начальнигы.

Л. Н. Газизуллина җитәкчелек иткән коллектив хезмәтне оештыруның алдынгы ысулларын уңышлы куллана. Ә бу хезмәт дисциплинасын ныгытуга, план заданиеләрен срогыннан элек үтәүгә булыша.

УЛ КПСС райкомының бюро члены, халык депутатларының район Советы депутаты.

Л. Н. Газизуллина тимер юл транспортында ирешкән уңышлары өчен «Мактаулы тимер юлчы» дигән югары исемгә лаек булды. Аның хезмәтләре бик күп Мактау грамоталары, котлаулар белән билгеләп үтелде.

Куйбышев тимер юлының Норлат станциясе коллективы 226 номерлы Завод сайлау округы буенча Любовь Никифоровна Газизуллинаны Татарстан АССРга халык депутатлыгына кандидат итеп күрсәтте.

## Л. Н. Газизуллинаның сайлау алды платформасының төп положениеләре

Мин үземнең депутатлык эшчәнлегем программасына хезмәт кешеләренең тормыш шартларын яхшыртуга юнәлдерелгән планнарны реализацияләүгә булышлык итүче мәсьәләләрне кертәм.

Районны тимер юлчылар һәм шикәрчеләр поселокларын табигый газга тоташтыруда булышлык итүне беренче дәрәҗәдәге бурыч итеп саныйм. КПСС райкомы бюросы члены буларак, миңа авылларның яхшы юлларга булган ихтыяҗлары якын һәм аңлаешлы. Татарстанның 8 районына хезмәт күрсәтүче предприятие җитәкчесе буларак, гомуми файдаланудагы юлдан йөкләрне тиз алу кирәклеген дә яхшы аңлыйм. Норлат — Аксубай — Чистай, шулай ук район эчендә каты катламлы юллар төзүне тизләтүгә ярдәм итү өчен көчемне кызганмаячакмын.

Үз эшчәнлегемне «Торак» төзелеше программасының билгеләнгән срокларын үтәүгә юнәлдерәчәкмен, иске, җимерек өйләрне бетерү өчен көрәшәчәкмен.

Хатын-кыз, ана буларак, мине хатын-кызларның хезмәт һәм көнкүреш шартлары, аналарны һәм балаларны саклау мәсьәләләре борчый. Тимер юлда эшләүче хатын-кызларны авыр физик хезмәттән азат итеп, юл эшләрен механикалаштыруны, фермаларда азык тарату һәм башка эшләрне механикалаштыру буенча эшләрне якын елларда төгәлләү, балалар бакчалары, шифаханәләр төзү мәсьәләләрен хәл итү өстендә даими эшләячәкмен.

Социаль гаделлек принциплары сагында торуны үземнең депутатлык бурычым итеп санаячакмын, кешеләрнең үзгәртеп коруга булган ышанычына киртә куючыларны кисәтәчәкмен, административ-бюрократик системага каршы көрәшәчәкмен.

Бу һәм башка проблемаларны хәл итү өчен база булдыру кирәк. Моның өчен район тормышының һәр ягы турында мәгълүматлар тулы булырга тиеш. Чөнки район хезмәтчәннәре һәр вак-төяккә кадәр белеп торырга хаклылар. Тик тулы мәгълүматлык булганда гына алга куелган бурычларны хәл итүгә уйлап һәм аңлы рәвештә керешергә була.

Минем депутатлык эшемдә иң зур урынны сайлаучыларымның, бигрәк тә сугыш һәм хезмәт ветераннары, яшүсмерләрнең ихтыяҗлары урын алачак. Районда картлар йорты, яшүсмерләр өчен клублар төзү эшен тизләтүдә һәртөрле ярдәмне күрсәтергә тырышачакмын.

Бүген тормыш итү, яшәү урынына максимум әһәмият кирәклеге турында яхшы аңлыйм. Тирә-юнь мохитын саклауга һәртөрле булышлык күрсәтәчәкмен. Чөнки безнең Чирмешән һәм Кондырча елгаларыбызда җанлылык бетеп бара.

Киң җәмәгатьчелекне, барлык рангтагы җитәкчеләрне бу проблемаларны хәл итүгә тартырга тырышачакмын.

Билгеле, хәл ителмәгән мәсьәләләр бихисап, ләкин алар җәмәгатьчелек, округтагы сайлаучыларның актив булышлыгы белән генә хәл ителәчәк һәм мин моңа исәп тотам.

# Хатлардан юллар

Яңа 1990 ел әле башланды гына. Ә редакциягә килгән хатлар инде ике йөзгә якынлашты. Анда кешеләр узган ел нәтиҗәләре, быелгы елга старт турында сөенеп язалар. Врачларга, урта медицина персоналына рәхмәт хисләре белән тулы хатлар күп керә. Арада борчулы хатлар да аз түгел. Менә бүген шушы хатларның кайберләреннән юллар китереп үтәбез.

Норлат шәһәрендә яшәүче НУРИЯ ГОМӘРОВА күз врачы Мидхәт Гәрәевич Галиев һәм шәфкать туташларына үзенең чиксез рәхмәтен белдерә. Аның күзләренә операция ясаганнар һәм ул яңадан дөнья яктысын күрү бәхетенә ирешкән.

«Төрнәс» совхозында яшәүче ЕВГЕНИЙ ЕМЕЛЬЯНОВИЧ СТЕПАНОВ Мамык участок больницасының яшь теш врачы Татьяна Васильевна Волковага рәхмәт хисләре белән тулы хат җибәргән. «Врач әле яшь. Әмма кешеләргә карата игътибарлыгы, ярдәмгә килергә әзер торуы белән үзенә абруй казанды», дип яза.

Яңа Иглайдан ФӘҺИМӘ САТДАРОВА хаты невропатолог Зоя Петровна Веренцовага багышланган.

«Мин үзәк шифаханә стационарының неврология бүлегендә дәваландым. Бу бүлекнең врачы Зоя Петровна һәм шәфкать туташлары барысы да ачык йөзлеләр, тәмле телле, йомшак куллылар. Һәркемне сәламәтләндерү өчен тырышалар. Аларга эшләрендә уңышлар, нык сәламәтлек, шат көннәр телим», — дип яза Фәһимә Миннегалиевна.

«Мин II группа сугыш инвалиды. Яшем дә олы инде. Сугыш китергән гариплек мине гомерем буена сагалап килә. Елның күп өлешен больницада — врачлар, медицина сестралары ярдәмендә үткәрергә туры килә. Врачлар Галина Евгеньевна Фомина, Суфия Әгъзамовна Волкова, Роза Мөбиновна Фәхриева без картларны ачык йөз белән кабул итеп, тырышып дәвалыйлар. Барлык врачларга, медицина сестраларына һәм техник хезмәткәрләргә зур рәхмәт», — дип яза Норлат шәһәреннән ИСМӘГЫЙЛЬ ага СӨЛӘЙМАНОВ.

Бикүле авылы яшьләрен авыл культура йортында бернинди культура-масса эшләре алып барылмавы борчый икән.

«Авыл уртасында мәһабәт культура йорты бинасы утыра. Аның турында түбәсе биек, өйрәсе сыек, дияргә генә кала. Кичен яшьләр әнә шул клубка агыла. Яңа ел кичендә дә шулай булды. Балмаскарад, уеннар булыр дип өметләнгән идек. Бу кичне культура йорты мөдире ишекне ачып кертте, музыка уйный башлады. Уеннарны яшьләр үзләре оештырып җибәрде. Ләкин 21 сәгатьтә музыка тукталды, утлар сүндерелде. Директор Илшат Әһлиуллин халыкны куып чыгарды. Менә шулай каршы алды Бикүле яшьләре Яңа елны», — дип язалар бер төркем яшьләр.


**БЕЛДЕРҮ**

Норлат шикәр заводы түбәндәге һөнәрләр буенча эшчеләр чакыра: рафинад шикәре чыгару буенча автомат линияләре операторлары, слесарьлар, пар казаннары операторлары, ТЭЦ пар торбалары машинистлары, токарьлар, шоферлар, «Д» категорияле автобус йөртүчеләр, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар, грейфер краны машинистлары, тракторчылар, кладовщиклар, электромонтерлар, слесарь-сантехниклар, тулай торак дежурлары, балта осталары, ташчылар, чүкеч белән эшләүчеләр, калайчылар, йөк төяүче һәм бушатучылар.

Шикәр заводы түбәндәге белгечләрне чакыра.

Хезмәтне оештыру һәм нормалау буенча инженер, ТЭЦ мастеры, продуктлар бүлеге мастеры, капиталь төзелеш буенча инженер-проектлаучы.

Кадрлар бүлегенә мөрәҗәгать итәргә, телефон: 2—18—68.



РЕДАКТОР Ә. У. АБДУЛЛИН.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000. Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: редактор — 2—12—14, 2—22—81, редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь — 2—10—44, рус теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары — 2—14—16, чуваш теленә тәрҗемә буенча редактор урынбасары — 2—15—63, агропромышленность бүлеге — 2—22—51, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия — 2—18—67.

Газетаны Фидания Хәйретдинова җыйды.
Рима ГАНЕЕВА верстка ясады.
Клара Бобкова басты.
Корректор — Зөлфия Вәлиева.

Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТАССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме — 1 басма табак. Заказ 17. Тираж 3.867.